РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Тюлячи **КАРАР**

« » 27 ноябрь 2018 № 772

«Теләче муниципаль районының яхшы ирекле халык дружинасы» исеменә ел саен үткәрелә торган конкурс турында Нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 15 декабрендәге 20-54/15181 номерлы хатын үтәү йөзеннән, район халкының җәмәгать тәртибен саклауда катнашуының нәтиҗәлелеген арттыру, шулай ук ирекле халык дружиналарының актив әгъзаларын мораль яктан стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. «Теләче муниципаль районының яхшы ирекле халык дружинасы» исеменә еллык конкурс турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ә. Нурмөхәмматовка йөкләргә.

ОБЩИЙ ОТДЕЛ ГОМУМИ БҮЛЕГЕ

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «___» _______ 2018 № ____ карарына кушымта

**«Теләче муниципаль районының яхшы ирекле халык дружинасы» исеменә конкурс үткәрү турында нигезләмә**

*1. Конкурсның максатлары һәм бурычлары:*

- эшне активлаштыру, ирекле халык дружиналарының (алга таба - ИХД) нәтиҗәлелеген арттыру;
- ирекле халык дружиналарының эш тәҗрибәсен пропагандалау һәм тарату;
- ирекле халык дружиналары составында җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарны стимуллаштыру.

*2. Конкурста катнашучылар:*

- смотр-конкурста Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре төзегән ирекле халык дружиналары отрядлары катнаша.

*3. Конкурсның төп күрсәткечләре:*

- ИХД булдыру датасы;
- календарь елда ИХД кабул ителгән яңа әгъзалар;
- ИХД отряды эшен планлаштыру;
- ИХД отряды әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары турында белү;
- график нигезендә җәмәгать тәртибен саклау буенча рейдлар саны;
- рейдта ИХД әгъзаларының уртача чыгуы;
- җинаятьләрне булдырмый калуда, ачуда катнашу;
- Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Теләче районы буенча бүлекчәсенең балигъ булмаганнар эшләре инспекторы, Теләче муниципаль районы башкарма комитеты, башка хокук саклау һәм муниципаль органнар белән ИХД полиция участок уполномоченныйлары, юл-патруль хезмәте белән хезмәттәшлеге;
- Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Теләче районы буенча бүлеге башлыгы ИХД эше турында бәяләмә.

*4. Конкурсны уздыру тәртибе:*

Конкурска йомгак ясау Теләче районы халык дружиналары отрядлары арасында елга ике тапкыр уздырыла.

Конкурста җиңүчеләр өчен ИХД отрядлары арасында өч - 1 урыннар, 3 - 2 урыннар, 3 - 3 урыннар булдырыла.

ИХД отрядлары арасында смотр-конкурста җиңүчеләр ирекле халык дружиналары штабы утырышында билгеләнә.

*5. Конкурста катнашучыларны бүләкләү:*

1-3 урыннарны алган ирекле халык дружиналары һәм авыл җирлеге башлыклары Теләче муниципаль районы Башлыгының рәхмәт хатлары белән

бүләкләнәләр. ИД әгъзалары Теләче авылындагы "Дулкын" бассейнына баруга айлык абонементлар белән бүләкләнә:

1 урын - ИХД 3 әгъзасы + һәр ИХД әгъзасының 3 гаилә әгъзасы;

2 урын - ИХД 3 әгъзасы + һәр ИХД әгъзасының 2 гаилә әгъзасы;

3 урын - 3 ИХД әгъзасы.

6. Конкурс йомгаклары «Теләче» газетасында, Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә басылып чыга.